Language

Тел

Язык

# FOUNDATIONS OF TATAR LINGUISTICS IN THE WORKS OF KAYUM NASYRI (ON THE 190TH ANNIVERSARY OF THE SCHOLAR'S BIRTH)

**Gulshat Raisovna Galiullina,**
Kazan Federal University,
18 Kremlevskaya Str., Kazan, 420008, Russia,
Gulshat.Galiullina@ksu.ru.

**Alfiya Shaukatovna Yusupova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlevskaya Str., Kazan, 420008, Russia,
Alfiia.Iousoupova@kpfu.ru.

The article describes the scientific research of the outstanding educator, prominent scholar and encyclopaedist Kayum Nasyri in the area of Tatar linguistics. We know nine works by the scholar dedicated to different aspects of Tatar linguistics. It is necessary to specifically mention such works as *Anmuzazh*, one of the first grammars of Turkic languages which presents the rich scientific heritage of the Tatar language, a two-volume explanatory dictionary *Lehzhei tatari*, and the collection of spelling rules *Kawagyide kitabet*[1]. Unlike previous scientific publications, K.Nasyri's work did not follow the structure of Arab or Russian grammars, it tended to move away from the habitual and slightly outdated descriptions of linguistic facts. His most important achievement is the development of language norms and rules, based on the widespread models in the national spoken language. In general, K.Nasyri's research into linguistics is found in the following areas: lexis, grammar, terminology, etymology, and phonetics. In this article, we describe the scholar's studies in the areas of Tatar semasiology, onomastics, and lexicography.

**Key words**: the Tatar language, Kayum Nasyri, lexicology, lexicography, onomastica, terminology, spiritual culture of the Tatars.

Kayum Nasyri, who left an inimitable mark on Tatar science and whose versatile activity is of great interest today, worked in the areas of national education, pedagogy, the Tatar language, literature, culture, history, ethnography, archaeology, and social sciences. That is not all; he was among the first to acquaint the Tatar people with scientific

[1] see color insert to the article – *G.G. – A.Y.*

foundations of certain exact sciences, for instance, geography, mathematics, botany, and agriculture, through the first books written in Tatar. The scholar's encyclopedic activities as well as his talent for establishing interdisciplinary links are both characteristic features of K.Nasyri's research.

Kayum Nasyri was born on February 14, 1825 in the village of Verkhniye Shirdany of Sviyazhsky Uyezd in Kazan province[2]. The family instilled in him a desire for knowledge and a commitment to the Tatar language. In his memoirs he wrote that his grandfather Khusain had been *"very good at syntax"* [1: 4]. Every branch of his multifaceted linguistic research is worth a separate monographic study.

The scholar's studies of Tatar linguistics began in 1855 when he worked as a teacher of Tatar in the Kazan Theological Seminary. Later on, he continued his scientific research in the area of teaching Russian as a foreign language to the Tatar children.

K.Nasyri was among the first to raise the problem of reforming the Tatar language with the aim of creating a literary language understood by everyone. Throughout his more than a half-century literary and scientific research, K.Nasyri fought for the national character of the literary Tatar language. He worked hard in order to create the scientific basis of Tatar and to expand the boundaries of its practical use. In 1891-1896, K.Nasyri wrote *Anmuzazh*, a grammar book presenting the rich scientific heritage of the Tatar language among other Turkic languages, *Lehzhei tatari*, an explanatory dictionary, and *Kawagyide kitabet*, a collection of spelling rules. The fact that such significant works were created within such a short period of time is evidence of K.Nasyri's encyclopedic knowledge and the relevance of the work.

In 1895, *Anmuzazh* was published in the typography of Kazan University. Its structure is outlined in the introduction, where the author shows the reasons which induced him to write this work and he divides it into the following parts: phonetics, morphology and syntax.

In the part devoted to phonetics, K.Nasyri makes the classification of Tatar sounds. He writes that in Tatar the sounds are divided into vowels and consonants as in other languages. He shows 10 vowels in the Tatar language. It is well-known that I.Giganov was the first to suggest this idea after studying the amount of letters which designate vowels in the Russian alphabet. K.Nasyri added Tatar emphatic sounds of the Arab language to the 29 consonants of the Tatar language; however they did not find reflection in the classification. The linguist uses the Russian terms in his classification of the consonants, for example, labial consonants, guttural, sibilant, palatine, dental and nasal sounds. This classification differs from other existing variants as it is based on different principles.

The author identifies Oghuz elements in Tatar and provides examples to illustrate this phonetic phenomenon. He also points out mouth harmony produced by the sounds *'o-ö': 'koro, soro, börö'*, etc. The amount of work completed by the scholar is amazing: it would require the efforts of the whole institution to perform the task. Evidently, K. Nasyri made substantial contributions to the development of Tatar philology. Among his achievements are: the clarification of Tatar agglutination, the description of the main features and rich nature of Tatar parts of speech, especially the verb, classification of word endings according to the rules of derivation and the elaboration of spelling and pronunciation rules, which met the requirements of that time. In general, this work could be referred to the four main fields of linguistics: grammar, lexis, terminology, and etymology [2: 46]. In this article, we provide extensive coverage of K.Nasyri's research into the lexis of the Tatar language.

Although the scholar's works related to lexis and lexicography have already been studied to a certain extent, his research on semasiology has not been the focus of special studies. We have reasons to state that K.Nasyri's works contain scientific information on semasiology, though monographic studies of semasiology have just started. The scholar put a special focus on the polysemy of words and their semantic difference in *Kawagyide kitabet*, *Lehzhei tatari* and some other works. For example, *Kawagyide kitabet* contains the lexical entry called *Bash-danä ('a piece of head')* with the following information: *"They use the word head or Arabic 'räe'c more with regard to animals: one head of horse, two head of cow, five head of sheep. When it comes to bees, they say six head of alveary, meaning their houses. However, speaking about birds they say one piece of chicken, five pieces of duck. It is also true of food: two pieces of apples or the word with the similar meaning of piece is used instead"* [3: 305]. The scholar high-

[2] The famous turcologist N.K.Dmitriev compares the time of K.Nasyri's birth with the period of transition from the Middle Ages to the Renaissance and calls him a messenger of the Renaissance. See about this: Dmitriev N. K.Kayum Nasyri – philologist // Kayum Nasyri. 1825-1945: Materials of the Scientific Session devoted to the 120th anniversary of the scholar's birth. Kazan: Tatknigoizdat, 1948, p.39.

lights the fact that one or the other lexical unit can match the meaning of a certain concept and if used inappropriately, it may cause misunderstanding. For example, *"in our native tongue we say recover ('terelde') meaning getting well after general sickness, as for injuries the word heal (tözälde) is used"* [3: 307]; *"in our native tongue negative words and particles 'yuk, tügel, -syz' are used. In Arabic, they are 'lya, gayre'; and in Farsi: 'nä, bi'. But it is necessary to use these negative particles appropriately ..."* [3: 303]. Beyond all doubt, the scholar's work in this area is worth an in-depth study in the future.

K.Nasyri gathered incredibly rich material on Tatar onomastics. This research, which is connected with Tatar history and ethnography, later promoted the emergence of the Turkic-Tatar scientific school of onomastics.

Nowadays, the achievements of this scientific school are known not only in Russia, but also in the world onomastic community. Its rich history, which dates back to ancient times, continued into the 19$^{th}$ century. We can learn about that period from the notes of such travellers as Ahmad ibn Fadlan, the dictionary *Dīwānu l-Luġat al-Turk* (Arabic: '*Compendium of the languages of the Turks*') by Mahmud al-Kashgari, and the scientific ideas preserved in other sources. Beginning in the second half of the 19$^{th}$ century, Turk-Tatar onomastics underwent a period of data collection and study. The organization of the Society of Archaeology, History and Ethnography at Kazan University in 1878 was the impetus for studying the territory in which Tatars lived. Historical and ethnographic research meant collecting and studying the material of onomastics which was one of the main activities of this society. The fact that an onomastic club was organized and that its members were the famous scholars N.Ya.Agafonov, I.A.Baudouin de Courtenay, N.P.Zagoskin, I.A.Iznoskov, D.A.Korsakov, V.N.Polivanov, P.A.Ponomarev, V.V.Radlov, S.M.Shpilevskiy and others, proves of great interest to this sphere of linguistics. K.Nasyri was a non-degree student of Kazan University who took an active part in the work of the club and from 1885 he was known to be a full member [1].

Along with studying written documents and tombstones, and collecting folklore sources and Tatar myths, K.Nasyri gave his full attention to systematizing the information on the history of different villages, territories or regions. For example, the facts about small villages of his native land Sviyazhsky Uyezd and the town of Sviyazhsk written down by K.Nasyri are a valuable source for such areas of Tatar onomastics as toponymy, anthroponymy, and ethnonymics. He gave special attention to collecting different genealogical trees. For instance, the prophets' genealogical tree and his own, which began with his father Gabdelnasyr, are kept in the library of Kazan University among his other manuscripts. His family tree is presented in the form of a horse: the eldest relative Gabdelkhay was in the head of the horse and Kayum Nasyri himself was in its front leg, which was put forward [4: 15]. The scholar also conducted an etymologic analysis of separate toponyms. He explained the etymology of the name of his home village Shyrdan as a clipped phrase *"came from the city"* (Tatar: *shähärdän kilgäən*). Thus were called the founders of the village who were from Bolgar. With time, the phrase became shortened in colloquial speech. Family trees were also an essential source for Tatar onomastics because of the Turkic names, which were popular among the Turk-Tatars.

K.Nasyri's work *History of the Villages of Sviyazhsky Uyezd* is fully devoted to the origin of the villages, their development and the etymology of their names. The information about each village forms a separate article. The scholar analyses the history and toponymy of 21 villages after a comprehensive study of the epitaphs (hic jacets), historical folk tales, legends, manuscripts, genealogic trees, and toponyms. Every article has the same structure: the origin of the village, the information about its founder (most of the analyzed village names came from the name of its founder) and his family tree, its geographical characteristics, the papers related to the history of the village, the review of the epitaphs and other sources, some artifacts of oral folk arts and important microtoponyms. This method of presenting onomastic material suggested by K.Nasyri is also effectively used at the present time. Based on his studies of genealogic trees, K.Nasyri expresses his ideas about the ethnogenesis of the Tatars. Particularly interesting are his thoughts about the influence of Bolgar tribes on the formation of Kazan Tatars and the influence of certain tribes living in the Middle Volga and the Kama on their rise as a nation.

As already stated, K.Nasyri's work on compiling dictionaries is of singular value. Apart from *Lehzhei tatari*, which is invaluable in Tatar linguistics, the scholar effectively worked on compiling bilingual dictionaries. Though his work on the *Tatar-Russian dictionary* (*'Tatarcha-ruscha lögat' kitaby'*) began in 1859, it was published only in 1878 with the help of the merchant Fatkhulla Amashev

[5: 80]. The dictionary, which has 2923 words on 120 pages, was written with the aim of teaching Russian to the Tatars and Tatar to the Russians. According to the scholars and teachers of the present, 1500-3000 words of this dictionary are considered to be a lexical base (basic vocabulary), which is enough to speak the language fluently. K.Nasyri proved this idea 120 years ago relying on his own pedagogical experience. In the introduction to the *Tatar-Russian Dictionary* he gives short introduction to the phonetics of the Tatar and Russian languages: there are such parts as "Moving letters in the Russian alphabet", "Syllables" and "About stress". He writes: "*We are to use our three letters for several Russian vowel letters, which is impossible*". He also mentions that in the Russian language there are two types of letters: capital (big) and lowercase (small), and the words are written from left to right. He identifies similar and different features in syllables and stress in these two languages. He also emphasizes that in the Tatar language stress usually comes at the end of the word and in Russian it falls on different syllables, which can change the meaning of the word. *"They have some words written in the same way, but they can have different meanings depending on the stress. In such situations it is necessary to mark the stress. For example*: *gazab – m'uka ('torture'), on – muk'a ('flour')* [6: 3].

In the last part of the introduction titled "Which letters can replace Russian letters" the Russian ABC is provided. The author recommends his readers to get acquainted with the introduction of the dictionary and pay attention to the information given there: *"Let the man who wants to make good use of this dictionary, read the introduction to the book and know how to use letters and signs"* [6: 4]. As we see, this introduction is a useful methodological guide for the learners of Tatar written by the scholar in a clear and efficient manner.

The structure of the dictionary is similar to modern publications as the words are arranged in alphabetical order and this applies not only to the first letter, but to the second one as well. The words are given in four columns, as was common in the 19th century: Tatar words are listed alphabetically in the first column in Arabic script, the second column has the transliteration of these words in the Cyrillic alphabet, the third column gives the translation of the words and in the fourth column there are Russian words written in Arabic script. Being used widely in the 19th century, this method is found in other Tatar self-study books. The scholars tried to reflect the spelling and pronunciation features of both languages as well as their phonetic potential to make for easier learning.

K.Nasyri's *Russian-Tatar Dictionary* (1892) is deemed to be a particularly outstanding lexicographic work among the dictionaries compiled in the second half of the 19$^{th}$ century. The full name of this 264-page dictionary is *the Full Russian-Tatar Dictionary with the Appendix of Foreign Words Used in the Russian Language as Terms*. *"Kayum Nasyri compiled this dictionary as an aid or a reference book for the Tatars learning Russian"* [5: 82]. In the introduction titled "A Few Recommendations for Russian Language Learners" the author mentions his 35-year experience of teaching languages and suggests the idea that "we haven't had language learning until now" [7: 4]. Here, the educator and scholar gives advice to Russian language learners and sets four conditions of successful language acquisition:

– to learn separate words, to master them bit by bit as when you are gathering berries without noticing that your basket is full;

– to get acquainted with the pronunciation of the words;

– to learn morphology and syntax of the target language;

– to take into account the features of Russian prefixes [7: 5].

In K.Nasyri's opinion, *"it is wrong to learn the language only to be able to write the address on envelopes because such learners will never succeed in mastering the language"*, and he suggests the comparative method as a base for learning languages. The scholar's advice and guidance have not lost their relevance today.

The dictionary also has words of Slavic origin and foreign borrowings used in the Russian literary language of that time. The author writes about this on the front page: *"We have given a detailed description of meanings of Russian words, verbs with prepositions and prefixes, and we have properly explained the meanings of every such verb. We note that excepting Russian words there are foreign words used in the Russian language – they are mostly the terms related to different sciences"* [7: 2].

The *Russian-Tatar Dictionary* has about 20 thousand words; they are listed according to the Russian alphabet and written according to the spelling rules of that time. Translated words are given in Arabic script. The last page of the dictionary gives a table showing on which page the words with the same first letter are found. K.Nasyri thus

arranged the technical structure of the dictionary in the same way as advanced Russian dictionaries of the time.

At the end of the "Russian-Tatar Dictionary" the linguist places a little glossary of the terms and words borrowed from other languages which is called "Loan words". There are about 1700 socio-political and scientific-technical terms, such as: *artillery, anthropology, barometer, biscuit, ventilator, didactics, Consul, a lancet, a manuscript, landscape, micrograph, neurology, spelling, planet raid, reform, rhetoric, system, text, temperament, chronograph, photography expert, etiquette, ether, cylinder, jubiljar,* and others. The fact that these Russian loan words were explained and translated into Tatar increases the value of the dictionary and this was a great innovation for that time.

In 1939, the journal of *Soviet Literature* published an article in which the dictionary was criticized owing to the influence of the ideology of that time and on the assumption of social class principles. It wrote: *"K.Nasyri's dictionary does not meet the demands of the present time. It cannot satisfy even the requirements of workers, collective farmers and peasants who read modern literature, newspapers and journals"* [8: 101]. The authors also blamed the scholar for "*the absence of such words as radio, tractor, combine-harvester, and train in the dictionary; they found the explanation of certain new words ridiculous and the description of word meanings too long*" [8: 101]. However, this was the only major dictionary in relation to the number of words, its type with a number of methods used in translating the words and the features of both languages presented in a comparative aspect. It was the only valuable aid containing instructions for foreign language learners.

Consequently, Kayum Nasyri was one of the founders of Tatar linguistics who laid the foundation for every area of linguistic research. Of course, it is impossible to comprehensively evaluate the whole multifaceted activity of the scholar in one article. Though the works of the outstanding scholar K.Nasyri, who served the Tatar people all his life, have been studied fairly well, his heritage is still worthy of profound research. In his works, every new scholar will be able to see the origin of scientific innovations and base their research on his works with the aim to improve Tatar philology.

**References**


1. *Gaynullin M.* Kayum Nasyyri (tormyshy häm izhaty) // Kayum Nasyyri. 1825-1945: tuuyna 120 el tuluga bagyshlangan gyyl'mi sessiya mater.: Mäžmuga. Kazan: Tatgosizdat, 1948. 3-41 b. (in Tatar)
2. *Dmitriev N.K.* Kayum Nasyyri – filolog // Kayum Nasyyri. 1825-1945: tuuyna 120 el tuluga bagyshlangan gyyl'mi sessiya materiallary. Kazan: Tatgosizdat, 1948. 41-61 b. (in Tatar)
3. *Nasyyri K.* Saylanma äsärlär. 4 tomda. 3 tom. Kazan: Tatar. kit. näshr., 2005. 382 b. (in Tatar)
4. *Nogman M.* N.I. Lobachevskiy isemendäge fänni kitapkhanä kul"yazmalarynyŋ tasvirlamasy. III chygarylysh. Kayum Nasyyri kul"yazmalary. Kazan, 1958. 48 b. (in Tatar)
5. *Khangildin V.N.* Kayum Nasyyri häm tatar leksikografiyase // Kayum Nasyyri: 1825-1845: Tuuyna 120 el tuluga bagyshlangan gyyl'mi sessiya mater.: Mäžmuga. Kazan: Tatgosizdat, 1948. B.78-91. (in Tatar)
6. *Nasyri K.* Tatarsko-russkiy slovar'. Kazan', 1878. 120 s. (in Russian)
7. *Nasyri K.* Polnyy russko-tatarskiy slovar' s dopolneniem iz inostrannykh slov, upotreblyaemykh v russkom yazyke kak nauchnye terminy. Kazan', 1892. 263 s. (in Russian)
8. *Yusupova A.Sh.* Dvuyazychnye slovari tatarskogo yazyka 19 veka. Kazan': Izd-vo Kazan. un-ta, 2008. 410 s. (in Russian)


**List of illustrations**

1. K.Nasyri. Translated by Kabusname. Kazan: *Tipolithography* of the Imperial University, 1867.
2. K.Nasyri. Lehzhei Tatars. Kazan: *Tipolithography* of the Imperial University, 1895.
3. K.Nasyri. Full Russian-Tatar dictionary. Kazan: *Tipolithography* of the Imperial University, 1904.
4. K.Nasyri. Tatar-Russian dictionary, 1875.

# КАЮМ НАСЫЙРИ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕ НИГЕЗЛӘРЕ (ГАЛИМНЕҢ ТУУЫНА 190 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН)

**Гөлшат Рәис кызы Галиуллина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Gulshat.Galiullina@ksu.ru.

**Әлфия Шәүкәт кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
Alfiia.Iousoupova@kpfu.ru.

Мәкаләдә татар халкының бөек мәгърифәтчесе, күренекле галим-энциплопедист Каюм Насыйриның татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге яктыртыла. Галимнең татар тел белеменә багышланган тугыз хезмәте билгеле. Тюркологиядә беренчеләрдән саналып, татар теленең өйрәнелү тарихы байлыгын күрсәткән «Әнмүзәҗ» грамматикасы, «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлеге, «Кавагыйде китабәт» орфографик кагыйдәләр китабы аерым игътибарга лаек[1]. Элгәрге авторлардан аермалы буларак, К.Насыйри теге яки бу телнең грамматикасына тулысынча иярми, калыплашкан, беркадәр архаиклашкан формалардан китәргә омтыла, иң мөһиме – халыкның җанлы сөйләм телен, аның формаларын үзәккә алып, тел кагыйдәләрен шулар нигезендә эшләүне алга сөрә. Гомумән алганда, К.Насыйриның тел белемендәге эшчәнлеге лексика, грамматика, терминология, этимология, фонетика өлкәләренә карый. Мәкаләдә галимнең лексикология өлкәсендәге хезмәтләренә аерым басым ясалып, аның татар теленең семасиологиясе, ономастика һәм лексикографиясе тармакларын үстерүгә керткән өлеше тикшерелә.

**Төп төшенчәләр:** татар теле, Каюм Насыйри, лексикология, лексикография, ономастика, терминология, татар халкының рухи мәдәнияте.

Татар фәнендә кабатланмас эз калдырган, киңкырлы эшчәнлеге бүген дә зур игътибарга лаек булган олы галим Каюм Насыйри милли тәрбия һәм белем бирү, татар теле, әдәбият һәм мәдәният, тарих, этнография, археология һәм җәмгыять фәннәре өлкәләрендә эшли. Ул гына да түгел, төгәл фәннәр, аерым алганда, география, математика, ботаника, игенчелек буенча татар телендә китаплар язып, беренчеләрдән булып, аларның гыйльми нигезләре белән татар халкын таныштыра. Галим эшчәнлегенең энциклопедик характеры, фәнара бәйләнешләрне эчке тоемлап, аларны отышлы куллану осталыгы үзе эшләгән һәр өлкәдә чагылыш таба.

Габделкаюм Габденнасыйр улы 1825 нче елның 14 февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туа[2]. Белемгә зур омтылыш, татар теле белән тирәнтен кызыксыну галимгә гаиләсендә үк салынган була. Үзенең истәлекләрендә ул бабасы Хөсәенне «нәхү гыйлеменә бик маһир кеше» [1: 4], дип яза. Каюм Насыйриның тел белеменә караган киң һәм универсаль эшчәнлегенең һәр тармагы аерым монографик эзләнүләргә лаек.

Галимнең татар тел белеме өлкәсендә эшчәнлеге 1855 нче елда Духовное училищеда татар теле укытучысы булып эшли башлаган чорга барып тоташа. Соңрак гамәли эшчәнлеге татар балаларына рус телен өйрәтү юнәлешендә дәвам итә.

К.Насыйри, иң беренчеләрдән булып, һәркемгә аңлаешлы татар әдәби телен булдыру мәсьәләсен күтәреп чыга. Үзенең ярты гасырга

[1] Мәкаләгә иллюстрацияне төсле кушымтадан кара – *Г.Г. – Ә.Ю.*

[2] Күренекле тюрколог Н.К.Дмитриев К.Насыйриның дөньяга килү вакытын, урта гасырлардан яңа дәвергә күчү чорына тиңләп, яңарыш хәбәрчесе дип атый. Бу турыда тулырак кара: Дмитриев Н.К. Каюм Насыйри – филолог // Каюм Насыйри. 1825-1945: тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. 39 б.

сузылган фәнни һәм әдәби эшчәнлегендә татар әдәби теленең халыкчанлыгы өчен көрәшә, аның фәнни нигезләрен булдыру, гамәли яктан куллану чикләрен киңәйтү юнәлешендә фидакарьләрчә эшчәнлек алып бара. Төрки телләр арасында татар теленең фәнни эшләнеше тарихының байлыгын раслаган «Әнмүзәҗ» грамматикасы, «Ләһҗәи татари» аңлатмалы сүзлеге, «Кавагыйде китабәт» кебек орфографик кагыйдәләр китабы бик аз вакыт эчендә, 1891-1896 нчы елларда басыла. Әлеге вакыт аралыгында шул дәрәҗәдә саллы, фәнни хезмәтләр әзерләү К.Насыйриның энциклопедик белем киңлеген, масштаблыгын дәлилли.

1895 нче елда Казан университеты типографиясендә басылып чыккан «Әнмүзәҗ» китабының төзелешен хезмәтне язуга этәргән сәбәпләр күрсәтелгән кереш мәкалә, фонетика, морфология һәм синтаксис өлешләре билгели.

Фонетика бүлегендә татар телендәге авазларга классификация ясала, башка телләрдәге кебек үк, татар телендә дә авазларның тартыкларга һәм сузыкларга бүленүе хакында бәян ителә. Каюм Насыйри татар телендә 10 сузык авазны күрсәтә. Билгеле булганча, бу фикер беренче тапкыр И.Гиганов тарафыннан рус алфавитындагы сузык авазларны белдергән хәрефләр саныннан гына чыгып әйтелгән була. Татар телендәге 29 тартык авазлар составына Каюм Насыйри гарәп теленнән кергән эмфатик авазларны да кертә, ләкин алар классификациядә чагылыш тапмый. Тартыклар классификациясендә тел галиме рус теле терминнары белән эш итә. Мәсәлән, согласные губные – ирен тартыклары, гортанные – бугаз тартыклары, свистящие – сызгыра торган авазлар, небные – аңкау авазлары, зубные – теш тартыклары, носовые – борын тартыклары. Бу төркемләүдә төрле принциплар кушыла, шулай да авторның тартыклар классификациясе башкалардан фәннилеге белән аерылып тора.

Автор татар телендәге угыз элементларын мисаллар ярдәмендә күрсәтә. Алга таба *о-ө* авазларының ирен гармониясе барлыкка китерүе ассызыклана: *коро, соро, бөрө* һ.б. Үзенең грамматикаларында татар теленең агглютинатив характерын ачыклау, сүз төркемнәрен, аеруча фигыль сүз төркеменең төп сыйфатларын, бай табигатен ачу, сүз ясалышына бәйле кушымчаларны төркемләү, заман таләпләрен исәпкә алган орфографик һәм орфоэпик кагыйдәләр булдыру кебек һәрберсе бер институт башкарырлык гамәлләрен атау гына да галимнең татар филологиясе фәне үсешенә керткән өлешенең зурлыгын раслый. Гомуми планда исә бу эшчәнлекне төп дүрт тармакка: грамматика, лексика, терминология һәм этимологиягә берләштереп булыр иде [2: 46]. Әлеге мәкаләдә К.Насыйриның татар теле лексикасына бәйле эшчәнлеге киңрәк яктыртыла.

Татар тел белемендә галимнең лексикага һәм лексикографиягә багышланган хезмәтләре билгеле бер күләмдә тикшерелсә дә, аның семасиологиягә караган эшчәнлеге аерым яктыртылмаган. Күзәтүләр соңгы елларда гына монографик планда өйрәнелә башлаган семасиология тармагына кагылышлы фәнни мәгълүматларның К.Насыйрида инде шактый урын алуын күрсәтә. Галим үзенең «Кавагыйде китабәт», «Ләһҗәи татари» һәм башка китапларында сүзләрнең мәгънә киңлегенә, аларның мәгънәви аермаларына махсус туктала. Мәсәлән, «Кавагыйде китабәт» хезмәтенең *Баш-данә* дип исемләнгән сүзлекчәсендә түбәндәге мәгълүмат бирелә: «Баш яки гарәпчә рәәс дип сөйләшерләр, хайванат әһле хакында күбрәк мөстәгъмәлдер. Мәсәлән, бер баш ат, ике баш сыер, биш баш сарык. Вә бал корты хакында, йортларын зикер кылып, алты баш умарта, диерләр. Әмма кошлар җөмләсеннән бер данә тавык, биш данә үрдәк, диерләр. Шулай ук ашамлыктан ике данә алма, вә гадәд (сан) сүзенең истигъмале кәзалик данә сүзе кебектер...» [3: 305]. Галим теге яки бу лексик берәмлекнең, мәгънәсенә карап, аерым төшенчәгә берегүен, сүзне урынсыз кулланганда, аңлашылмаучанлыкка китерүенә дә басым ясый, мәсәлән, «... үз телебездә эчтәге авыру хакында *терелде* вә һәм җәрәхәт хакында *төзәлде* дип сөйләшәбез» [3: 307]; «үз телебездә мәүҗүд нәфи хәрефләр ошбулардыр: *юк, түгел, -сыз*. Дәхи гарәптән: *ля, гайре*; вә фарсыдан: *нә, би* хәрефләре мөстәгъмәлдер. Әмма ошбу әдат нәфиләрне урынына күрә куллана белү тиештер...» [3: 303] һ.б. Галимнең бу өлкәдәге эшчәнлеге киләчәктә җентекле өйрәнелүгә, һичшиксез, лаек.

К.Насыйри татар ономастикасы тармагына караган гаҗәеп бай мәгълүмат туплый. Татар тарихы, этнографиясе өлкәсендәге эшчәнлеге белән үрелеп барган бу гамәл соңрак татар тел белемендә зур бер фәнара тармак саналган ономастика фәне барлыкка килүгә, төрки-татар ономастика гыйльми мәктәбе формалашу һәм үсүгә зур этәргеч була.

Бүгенге көндә әлеге мәктәпнең казанышлары Россиядә генә түгел, дөнья ономастикасы фәнендә дә билгеле. Аның бай тарихы борынгы чорлардан башланып, XIX гасыр уртасына кадәр дәвам итә. Бу чор турында Ибн-Фадлан кебек сәяхәтчеләр язмалары, М.Кашгарыйның «Диване лөгать эт-төрк» хезмәтләре һәм башка чыганакларда сакланган гыйльми күзаллаулар аша фикер йөртеп була. XIX гасырның икенче яртысыннан төрки-татар ономастикасына караган фәнни мәгълүматларны системалы туплау һәм эшкәртү чоры башлана. 1878 нче елда Казан университетында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оешу төбәкне өйрәнүгә гаять зур этәргеч була. Тарихи-этнографик тикшеренүләр алып бару, шул исәптән ономастик материал туплау һәм аны өйрәнү җәмгыятьнең төп эшчәнлекләреннән берсе булып тора. Җәмгыять каршында ономастик түгәрәк оешып, аның составына күренекле галимнәр Н.Я.Агафонов, И.А.Бодуэн-де-Куртенэ, Н.П.Загоскин, И.А.Износков, Д.А.Корсаков, В.Н.Поливанов, П.А.Пономарев, В.В.Радлов, С.М.Шпилевский һәм башкалар керү әлеге өлкәгә игътибарның зур булуын дәлилли. Казан университетында ирекле тыңлаучы буларак белем алган К.Насыйри Җәмгыять эшендә актив катнаша башлый һәм 1885 нче елдан ул аның хакыйкый әгъзасы булып санала [1].

Татар мифологиясе, фольклорына бәйле чыганакларны туплау, кабер ташларын, язма документларны тикшерү белән беррәттән, К.Насыйри теге яки бу төбәк, авыл тарихына караган мәгълүматларны барлауга һәм системалаштыруга да зур игътибар бирә. Мисал өчен, үзенең туган төбәге Зөя өязенең аерым бер авыллары һәм Зөя каласы турындагы материаллары татар ономастикасының топонимия һәм антропонимия, этнонимия тармаклары өчен кыйммәтле чыганак булып торалар. К.Насыйри төрле шәҗәрәләр туплауга аерым игътибар бирә. Мәсәлән, аның Казан университеты китапханәсендәге кульязмалары арасында пәйгамбәрләр шәҗәрәсе һәм атасы Габденнасыйрдан башланган нәсел шәҗәрәсе саклана. Бу шәҗәрә ат кыяфәтендә эшләнеп, иң олы туганнары Габделхәй атның башы итеп күрсәтелсә, Каюм Насыйри исә атның алгы аякларының алга таба атлаганы рәвешендә бирелә [4: 15]. Галим аерым топонимик берәмлекләргә этимологик анализ да биреп бара. Үзенең туган авылы атамасы *Шырдан* сүзен ул Болгардан килеп авылга нигез салучыларны «шәһәрдән килгәннәр» дип атаганнар, сөйләмдә алар вакытлар үтү белән кыскарып Шырдан булып киткән, дип аңлата. Төрки-татарлар арасында йөргән төрки исемнәрнең бирелеше дә шәҗәрәләрнең татар ономастикасы өчен кыйммәтле чыганак булуын раслый.

К.Насыйриның «Зөя өязе авыллары» хезмәте тулысы белән авылларның барлыкка килүе, үсеше, атамаларының килеп чыгышын ачыклауга багышланган. Һәр авылга бәйле мәгълүмат аерым бер мәкалә буларак формалаштырылган. Эпитафик язмаларны, тарихи риваятьләрне, кульязма документларны, шәҗәрә һәм топонимнарны комплекслы өйрәнеп, галим 21 авыл тарихын һәм топонимиясен анализлый. Һәр мәкалә уртак төзелешкә ия: авыл барлыкка килү, аңа нигез салган кеше турында мәгълүмат (галим анализлаган авылларның зур күпчелеге, нигездә, кеше исеменә нисбәтле барлыкка килгән) һәм аның шәҗәрәсе, географик характеристика, авыл тарихына караган документ, каберташ язмаларына, башка чыганакларга күзәтү, халык авыз иҗатыннан китерелгән кайбер ядкәрләр, әһәмиятле роль уйнаган микротопонимнарны күрсәтү. К.Насыйри тарафыннан тәкъдим ителгән бу алым хәзерге көндә дә ономастик материалны бәян итүдә нәтиҗәле кулланыла. Өйрәнелгән шәҗәрәләр нигезендә К.Насыйри татар халкының этногенезына кагылышлы фикерләрен дә белдерә, аерым алганда, казан татарлары формалашуда болгар кабиләләренең роле, милләт-кавем буларак оешуга Урта Идел һәм Кама буенда яшәгән башка кабиләләрнең йогынтысы турындагы фикерләре игътибарга лаек.

Каюм Насыйриның, югарыда әйтелгәнчә, сүзлекләр төзү өлкәсендәге эшчәнлеге аерым әһәмияткә ия. Татар тел гыйлеме фәнендә бәһасез кыйммәткә ия булган «Ләһҗәи татари» хезмәтеннән тыш, галим ике телле сүзлекләр төзү юнәлешендә дә нәтиҗәле эш алып бара. К.Насыйриның «Татарча-русча лөгать китабы» 1859 нчы елда ук төзелә башласа да, бик соң басылып чыга [5: 80]. Бу сүзлек, югарыда әйтелгәнчә, сәүдәгәр Фәтхулла Хәмидулла улы Амашевның ярдәме белән 1878 нче елда басылып чыга. 2923 сүзне үз эченә алган 120 битлек сүзлек татарларга рус теле, русларга татар телен өйрәтү максаты белән төзелә. Хәзерге чор галимнәре һәм укытучылар

карашынча, 1500-3000 сүз, теге яки бу телдә иркен аралашу өчен, җитәрлек лексик база булып санала. К.Насыйри, үзенең укыту тәҗрибәсеннән чыгып, әлеге фикерне инде 120 ел элек дәлилләгән була. «Татарча-русча лөгать»нең керешендә К.Насыйри татар һәм рус телләре фонетикасы турында кыскача мәгълүмат бирә: «Рус азбукасында хәрәкәттә йөри торган хәрефләр», «Слоглар», «Ударение бәянында» дигән бүлекләр булу шул турыда сөйли. «Урысның берничә төрле гласный хәрефләре өчен бары үземезнең шул өч хәрефемезне истигъмаль кылмак кирәк, әмма бу мөмкин түгел», – ди К.Насыйри. Рус телендә хәрефләрнең ике төрле, ягъни баш (зур) һәм юл (вак) хәрефләре булуын, сулдан-уңга язылуын да искәртеп үтә. Бу ике телдә иҗек һәм басымның уртак һәм үзенчәлекле якларын билгели. Басымның татар телендә, гадәттә, сүз ахырында, ә рус телендә исә төрле иҗектә килә алуын һәм басымга карап мәгънә үзгәрешен ассызыклый: «Аларның бәгъзе кәлимәләре бар, бер рәвешле языла, әмма ударениесенә карап, мәгънәгә дәләләт кыйладыр. Мондаен хосусларда алар ударение галәмәтен куймакны зарур күрәләр. Мәсәлән: *газаб – мука, он – мука*» [6: 3].

Керешнең соңгы өлешендә «Урыс хәрефләренең кайсы хәрефләр бәрабәренә әйтелүе» дигән исем астында алфавит тәкъдим ителә. Хезмәт авторы укучыга сүзлекнең кереш өлеше белән танышырга һәм анда әйтелгән фикерләргә игътибар итәргә кирәклеген искәртә: «Бу лөгать китабыннан бер файда хасил итим дигән адәм ошбу безнең язылмыш мөкаддимәмезне мөтәләга кыйлып (укып), үз галәмәтләренең вадигын (куелышын) белсеннәр» [6: 4]. Күренә ки, татар телен өйрәнүчеләргә файдалы методик әсбапның кереш сүзе галим тарафыннан бик уңышлы һәм үтемле язылган.

Бу сүзлек үзенең төзелеш принциплары белән дә хәзерге сүзлекләргә бик якын. Анда сүзләр алфавит тәртибендә урнаштырылып, әлеге тәртип сүзнең беренче хәрефенә генә түгел, аннан соң килгәннәренә дә карый. Сүзләр XIX гасырда киң кулланылышта булган дүрт баганага бүленеп бирелә: беренче баганада гарәп алфавиты тәртибендә, гарәп графикасында татарча сүз урнаштырыла; икенчесендә – сүзнең рус хәрефләре белән транслитерациясе; өченче баганада – сүзнең русчага тәрҗемәсе; дүртенче баганада рус сүзе гарәп хәрефләре белән китерелә. XIX гасырда киң кулланылышта булган бу алым татар теленең башка үзөйрәткечләрендә дә чагылыш таба. Галимнәр тел өйрәнүчеләр өчен ике телнең фонетик мөмкинлекләрен, әйтелеш һәм язылыш үзенчәлекләрен чагылдырырга тырышканнар. Әлбәттә, бу алым телне җиңелрәк үзләштерергә ярдәм иткән.

К.Насыйриның «Русча-татарча сүзлеге» (1892) XIX гасырның икенче яртысында төзелгән сүзлекләр арасында аеруча күренекле лексикографик хезмәтләрдән санала. 264 битлек иң күләмле сүзлекнең тулы атамасы – «Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как термины». «К.Насыйри бу сүзлекне турыдан-туры татарларга рус теле өйрәтү өчен белешмәлек, кулланма итеп төзегән» [5: 82]. «Русча өйрәнүчеләргә бераз нәсыйхәт» исемле кереш сүзендә автор бу хезмәтенең 35 еллык эш тәҗрибәсе икәнлеген ассызыклап, «бу вакытка кадәр бездә тел өйрәнү юк иде» [7: 4] дигән фикере белән уртаклаша. Бирелә мәгърифәтче галим рус телен өйрәнүчеләргә киңәшләр биреп, дүрт таләпне шарт итеп куя:

– аерым сүзләрне белү: аларны, җиләк җыйганда үзең дә сизмәстән чиләк тутырган шикелле, әкрен-әкрен үзләштерү;

– авазларның әйтелеше белән танышлык;

– өйрәнелә торган телнең морфология һәм синтаксисын белү;

– рус префиксларының үзенчәлекләрен исәпкә алу [7: 5].

К.Насыйри карашынча, «телне конвертларда адрес язу өчен генә өйрәнергә ярамый, чөнки мондый максаттан чыгып өйрәнүчеләр бервакытта да теләкләренә ирешә алмыйлар», һәм ул тел өйрәнүнең чагыштырма методка нигезләнгән булуын яклый. Авторның методик күрсәтмәләре һәм тәкъдим-киңәшләре бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмаган.

Сүзлеккә шул чор рус әдәби телендә кулланылган славян чыгышлы сүзләр һәм алынмалар теркәлгән. Бу турыда автор хезмәтенең титул битендә болай дип яза: «Рус кәлимәләренең мәгънәсе тәфсыйлән бәян кылынып, хәрфе җәрле (предлог, приставкалы) фигыльләр дә, вә дәхи һәрбер хәрфе җәрнең мәүзугы ләһ (үзенә хас) мәгънәләре дә тәфсыйлән бәян кылынды. Янә рус кәлимәләреннән башка рус телендә мөстәгъмәл булучы әҗнәби лөгатьләр (чит тел сүзләре) рус телендәге фөнүне шәтта истыйлахлары (төрле

фәннәргә караган атамалар) – күбрәк чит тел сүзләредер, зикер кылынды» [7: 2].

«Русча-татарча сүзлек»кә 20 меңгә якын берәмлек теркәлгән. Лөгатьлектә сүзләр рус алфавиты тәртибендә урнаштырылып, шул чор орфографиясе буенча язылган. Тәрҗемә өлешендәге сүзләр гарәп графикасында бирелгән. Китапның соңгы битендә һәр хәреф буенча сүзләрнең башланган бит санын күрсәткән таблица урнаштырылган. Шулай итеп, К.Насыйри сүзлекнең техник төзелешен дә заманының алдынгы рус сүзлекләре үрнәгендә формалаштырган.

«Русча-татарча сүзлек»нең ахырында тел галиме «Әлфаз әҗнәбия», ягъни «Чит сүзләр» дигән баш астында рус теленә башка телләрдән кергән сүзләр һәм терминнар сүзлекчәсе урнаштыра. Биредә *артиллерия, антропология, барометр, бисквит, вентилятор, дидактика, консул, ланцет, манускрипт, ландшафт, микрография, неврология, орфография, планета, рейд, реформа, риторика, система, текст, темперамент, хронография, фотография, эксперт, этикет, эфир, цилиндр, юбиляр* кебек 1700 гә якын иҗтимагый-сәяси, фәнни-техник терминнар урын ала. Рус телендәге бу алынмаларга татар телендә аңлатмалар бирү, тәрҗемә итү сүзлекнең кыйммәтен тагын да арттыра һәм бу күренеш үз чоры өчен зур яңалык булып тора.

1939 нчы елда «Совет әдәбияты» журналының бер санында дөнья күргән мәкаләдә, чор идеологиясе йогынтысында сыйнфый-социаль принциптан чыгып, сүзлеккә тискәре бәя бирелә. «Каюм Насыйриның русча-татарча бу сүзлегенең эчтәлеге хәзерге чор өчен шулкадәр ярлы, ул хәзерге чорда газета, журнал һәм әдәбият укып баручы эшче һәм колхозчы крестьяннарның кирәген дә үтәрлек түгел», – дип язып чыгалар. Мәкалә авторы галимне шулай ук «сүзлектә радио, трактор, комбайн, поезд кебек яңа сүзләр табып булмауда, булганнарын да көлкеле мәгънәдә бирүдә, бер сүз белән аңлатырлык кәлимәләрне озын җөмләләр белән аңлатуда» [8: 101] гаепләп чыга. Әмма К.Насыйриның бу сүзлеге теркәлгән сүзләренең саны, төре ягыннан да, сүзләрне тәрҗемә итүдә кулланган алымнар байлыгы белән дә, ике телнең үзенчәлекләрен чагыштырма планда күрсәтү юнәлешендә дә чит телне өйрәнүчеләргә кирәкле методик күрсәтмәләрне туплаган бердәнбер мөһим сүзлек була.

Димәк, Каюм Насыйри тел белеменең олы юл башында торып, аның һәр тармагына нигез сала. Әлбәттә, бер мәкаләдә генә галимнең киңкырлы эшчәнлеген бәяләп бетерү мөмкин түгел. Татар халкына гомере буе хезмәт иткән зур галим Каюм Насыйриның гыйльми хезмәтләре шактый өйрәнелсә дә, әле бу мираста тикшерелергә лаек катламнар бар. Һәр яңа дәвер галиме аның хезмәтләрендә фәнни яңалыкларга нисбәтле беренче чаткыларны күрә белергә, алга таба татар филология фәнен үстерүдә нигез итеп кулланырга тиеш.

**Әдәбият**


1. *Гайнуллин М.* Каюм Насыйри (тормышы һәм иҗаты) // Каюм Насыйри: 1825-1945: Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия матер. Казан: Татгосиздат, 1948. Б.3-41.
2. *Дмитриев Н.К.* Каюм Насыйри – филолог // Каюм Насыйри: 1825-1945: Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. Казан: Татгосиздат, 1948. Б.41-61.
3. *Каюм Насыйри.* Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 том. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 382 б.
4. *Ногман М.* Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә кульъязмаларының тасвирламасы. III чыгарылыш. Каюм Насыйри кульъязмалары. Казан, 1958. 48 б.
5. *Хангилдин В.Н.* Каюм Насыйри һәм татар лексикографиясе // Каюм Насыйри: 1825-1845: Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия матер. Казан: Татгосиздат, 1948. Б.78-91.
6. *Насыри К.* Татарско-русский словарь. Казань, 1878. 120 с.
7. *Насыри К.* Полный русско-татарский словарь с дополнением из иностранных слов, употребляемых в русском языке как научные термины. Казань, 1892. 263 с.
8. *Юсупова А.Ш.* Двуязычные словари татарского языка XIX века. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. 410 с.


**Иллюстрацияләр исемлеге**

1. К.Насыйри. Кабуснамә тәрҗемәсе. Казан: Типо-литографія Императорскаго Университета, 1867.
2. К.Насыйри. Ләһҗәи татари сүзлеге. Казан: Типо-литографія Императорскаго Университета, 1895.
3. К.Насыйри. Русча-татарча тулы сүзлек. Казан: Типо-литографія Императорскаго Университета, 1904.
4. К.Насыйри. Татарча-русча сүзлек, 1875.

# ОСНОВЫ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКОЗНАНИЯ В ТРУДАХ КАЮМА НАСЫРИ (К 190-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ)

**Гульшат Раисовна Галиуллина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, д.18,
Gulshat.Galiullina@ksu.ru.

**Альфия Шавкетовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г.Казань, ул.Кремлевская, д.18,
Alfiia.Iousoupova@kpfu.ru.

Статья посвящена описанию научной деятельности выдающегося просветителя, видного ученого-энциклопедиста Каюма Насыри в области татарского языкознания. Известно девять работ ученого, посвященных тем или иным аспектам татарского языкознания, среди которых особое место занимают одна из первых грамматик тюркских языков «Әнмүзәҗ», где представлена история татарского языкознания, двухтомный толковый словарь «Ләһҗәи татари» и сборник орфографических правил «Кавагыйде китабәт»[1]. В отличие от ранее опубликованных научных работ, К.Насыри не увлекается заимствованием структуры арабских или русских грамматик, а стремится отойти от привычных и слегка устаревших описаний языковых фактов, пропагандирует разработку языковых норм и правил, опираясь на распространенные в народном разговорном языке модели. Научное наследие К.Насыри представлено в таких разделах языкознания, как лексика, грамматика, терминология, этимология, фонетика. В данной статье описывается деятельность ученого в области татарской семасиологии, ономастики и лексикографии.

**Ключевые слова:** татарский язык, Каюм Насыри, лексикология, лексикография, ономастика, терминология, духовная культура татар.

**Список иллюстраций**

1. К.Насыри. Перевод Кабуснамэ. Казань: Типо-литографія Императорскаго Университета, 1867.
2. К.Насыри. Лэхжэи-татари. Казань: Типо-литографія Императорскаго Университета, 1895.
3. К.Насыри. Полный русско-татарский словарь. Казань: Типо-литографія Императорскаго Университета, 1904.
4. К.Насыри. Татарско-русский словарь, 1875.

[1] См. иллюстрации к статье на цветной вклейке – *Г.Г. – А.Ю.*